ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№1223 «11» 10 2017 ел

«2017 елга Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
территориясендә заманча шәһәр мохите
формалаштыру» муниципаль
программасы проекты буенча
иҗтимагый фикер алышу тәртибен
раслау турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә комплекслы төзекләндерү системасын камилләштерү һәм җәмәгать киңлекләрен үстерү буенча чараларны гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларына һәм уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру муниципаль программаларына ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 169 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.«2017 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә заманча шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасы проекты буенча иҗтимагый фикер алышу тәртибен расларга (1 нче кушымта).

1. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Р.К.Мөхәммәтҗанов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
«11» 10 2017 ел, № 1223 карарына
1 нче кушымта

«2017 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә заманча шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасы проекты буенча иҗтимагый фикер алышу тәртибе

1. «2017 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә заманча шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасы проекты буенча иҗтимагый фикер алышу тәртибе (алга таба- Тәртип, Программа) «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде.

2. Программа проектын иҗтимагый фикер алышу максатларында Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) рәсми сайтта http://mamadysh.tatarstan.ru/ «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җәмәгать фикер алышуын үткәрү турында хәбәрнамә урнаштыра.

Җәмәгать тикшерүен үткәрү турында хәбәрнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:
Программа проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр тапшыру срогы - Программа проекты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган көннән алып 30 көн

искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җибәрү өчен адрес;

Программа проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү ысулы;
җәмәгать фикер алышуы нәтиҗәләрен билгеләү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат;

гражданның фамилиясен, исемен һәм атасының исемен күрсәтү зарурлыгы, яисә кисәтүләр һәм тәкъдимнәр җибәргән оешманың исеме.

Җәмәгать фикер алышуын үткәрү турында хәбәрнамә белән бер үк вакытта Программа проекты http:/ madysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында урнаштырыла.

3. Программа проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү срогы тәмамланган көннән алып бер эш көне эчендә башкарма комитет Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча иҗтимагый комиссиягә җибәрә.

4. Программа проекты буенча кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кергән көннән алып бер эш көне эчендә иҗтимагый комиссия аларны бәяләүне үткәрә һәм, беркетмә тарафыннан рәсмиләштерелә торган барлык кисәтүләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, Программа проектын эшләп бетерү кирәклеге турында, йә беркетмә тарафыннан рәсмиләштерелә торган барлык искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне тайпылышлау турында карар кабул итә.

5. Беркетмә нигезендә башкарма комитет ике эш көне дәвамында Программа проектының ахыргы вариантын формалаштыра, аны http:/ mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында урнаштыра һәм аны билгеләнгән тәртиптә раслауга җибәрә.